**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5102**
**14.06.2023**

Муниципаль милектәге җир участогына карата сервитут (җәмәгать сервитуты) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 284-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 9 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары берлән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4421 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогына карата сервитут (җәмәгать сервитуты) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.8.2.1 пунктның 6 пунктчасына түбәндәге сүзләрне өстәп, үзгәреш кертергә:

«, линия объектлары булып торган инженерлык корылмаларын капиталь ремонтлау максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмалары участокларын (өлешләрен) капиталь ремонтлау максатларында җәмәгать сервитуты билгеләү очрагыннан тыш».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов